ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

19.09.2017г | с. Татарское Бурнашево | № 15

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты, 11 статья Борнаш авыл җирлеге Уставы,

Карар бирәм:

1. Борнаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның уртак инициативасын тәкъдим итү:

«Сез 2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару мәсьәләсен хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Татар Борнашы авылында Совет урамыннан Первомайская урамындагы чокыр аша җәяүлеләр күпере төзү;
- Гаврилково, Каинки, Ломовка, Тихий Плес, Юматово авылларында урнашкан зиратларны төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аны имзалаган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы Бурукин С.В.